УДК 398.22

*И.К. Фазлетдинов*

# БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ БӘЕТЛӘРЕНДӘ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВАКЫЙГАЛАРЫ ЧАГЫЛЫШЫ

Статья посвящена исследованию отражения событий Великой Отечественной войны в лиро-эпическом творчестве татарского населения Республики Башкортостан. Привлечен обширный, доселе непубликовавшийся материал из фольклорного фонда кафедры татарской филологии и культуры Уфимского университета науки и технологий. По особенностям художественного олицетворения описываемых событий и характеру лирического героя автор подразделяет данные произведения на две группы: фронтовые и тыловые баиты. Проведя тщательный анализ обеих групп, он отмечает то, что в фронтовых баитах преобладает эпическая и лиро-эпическая составляющая; а в тыловых баитах на первый план выходят лирические переживания сказителей. Отдельно анализируется преемственность в данных произведениях традиций баитов об Отечественной войне 1812 года и мотивов о лашманстве – заготовщиках корабельного леса первой половины XVIII века. По итогам проведенного исследования, автор приходит к выводу о том, что анализируемые произведения являются отражением реальных исторических фактов через призму народного восприятия, сочетающим в себе как панорамность изображения народного подвига, так и всю глубину его трагедии из-за безвозвратной потери сыновей и дочерей.

**Ключевые слова:** баит, Великая Отечественная война, татары Башкортостана, мотив, традиция, поэтика, жанр, преемственность, лиро-эпика.

The article is devoted to the study of the reflection of the events of the Great Patriotic War in the lyrical and epic works of the Tatar population of the Republic of Bashkortostan. Extensive, hitherto unpublished material from the folklore fund of the Department of Tatar Philology and Culture of the Ufa University of Science and Technology has been used. The author divides these works into two groups according to the peculiarities of the artistic personification of the events described and the character of the lyrical hero: frontline and rear baits. After conducting a thorough analysis of both groups the author notes that the epic and lyric-epic components prevail in the front baits; and in the rear baits the lyrical experiences of the storytellers come to the fore. The continuity in these works of the traditions of the Baites about the Patriotic War of 1812 and the motifs about the Lashmanism, the ship's timber harvesters of the first half of the XVIII century, is analyzed separately. Based on the results of the research, the author comes to the conclusion that the analyzed works are a reflection of real historical facts through the prism of popular perception, combining both the panoramic image of a national feat and the depth of its tragedy due to the irretrievable loss of sons and daughters.

**Keywords:** bait, the Great Patriotic War, the Tatars of Bashkortostan, motive, tradition, poetics, genre, continuity, lyric epic.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнүче «Татар халык иҗаты» 25 томлыгының ике китаптан торган «Бәетләр» тупланмасын эшләгәндә, Башкортстан татарлары фольклорына аерым игътибар бирелде. Бу уңайдан шуны әйтергә кирәк: әгәр 1983 елда чыккан «Бәетләр» академик томында Бөек Ватан сугышы турында Башкортстан җирлегендә язып алынган бер генә бәет урын алса («Бәбекәем, ак йөзкәем», Чакмагыш районы Аблай авылы) [6: 245], без әзерләгән ике томда аларның саны 10 га җитте. Әлеге үрнәкләрнең дүртесе – «Сугышта үлгән солдат бәете» [2: 241–242], «Солдат бәете» [2: 235], «Зөбәрҗәт бәете» [2: 253–254], «Ачлык чире бәете» [4: 210–211] – безнең тарафтан әзерләнеп, 2021 елда Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ тарафыннан бастырып чыгарылган «Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенең 3 нче китабында дөнья күрде. Калган бишесе – «Сугыш бәете», «Кайгылы хатын бәете», «Шәмсулла бәете», «Мөхәррәм бәете» «Сабырбикә бәете» – әлегә кадәр матбугатта нәшер ителмәгән. Алар Уфа Фән һәм технологияләр университеты (элекке Башкорт дәүләт университеты) татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасының фольклор фондында саклана.

Тарихтан күренгәнчә, XVIII–XX гасырлар Русия тарихында моңа кадәр күрелмәгән дәүләтара һәм илкүләм сугышларның күплеге белән аерылып тора. Билгеле, фаҗигалылыкка корылган жанр буларак бәет мондый канкоешлы вакыйгаларны халык күңеле, аның күз яше аша ачуны төп максаты итеп куя. Мондый бәетләр «гомум бәет фондының яртысыннан артыгын тәшкил итә» [5: 18] һәм берничә циклга бүленә. Мәсәлән: рус – француз, рус – төрек, рус – япон, Беренче бөтендөнья, гражданнар сугышлары турында бәетләр. Фәндә бу төр әсәрләр «хәрби-тарихи бәетләр» термины астында берләштерелә. Без тикшерә торган Бөек Ватан сугышы турындагы бәетләр дә нәкъ шушы төркемгә карый.

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышына багышланган бәетләрне без ике төркемгә бүләбез: «Фронт бәетләре» һәм «Тыл бәетләре»нә. Әлеге классификация әсәрдә барган вакыйгаларның географиясен һәм фольклор героеның хәрби «биографиясе»н генә чагылдырып калмый, биредә чынбарлыкны сәнгатьчә чагылдыруның үзгә принциплары да эш итә. Фронт бәетләренә, кагыйдә буларак, эпик һәм лиро-эпик сәнгать алымнары хас, ә тыл бәетләрендә лирик алымнар өстенлек итә.

Күренекле фольклор галиме Фатих Урманче шулай ук Бөек Ватан сугышына багышланган бәетләрне ике зур төркемгә бүлеп карый. «Беренче төркемгә ил тормышы, сугыш вакыйгалары белән бәйләнгән иҗтимагый эчтәлекле бәетләр керә («Дошманны җиңгәч кайтырбыз», «Германия сугыш ачты көтмәгәндә»), – ди ул. – Аларда сүз, нигездә, илдәге фаҗигалы вакыйгалар, солдатларның фронттагы батырлыклары, тылдагы халыкның җиңү өчен җан аямый эшләве турында бара. Бәетләрнең бу төркеме жанрның уңай традицияләренә таяна һәм

шуларны уңышлы дәвам итә» [7: 369]. Без тәкъдим иткән классификациягә таянганда, бу төр әсәрләр «фронт бәетләре» төркеменә карый булып чыга, чөнки аларда хикәяләү сугышта катнашучының үз исеменнән алып барыла; алар яугирләрнең үзләре, я сугышчан дуслары тарафыннан иҗат ителеп, әсәр герое һәлак булган очракта хат белән җибәреләә, яисә исән-имин автор белән бергә туган якка әйләнеп кайта. Поэтик сурәтләү алымнары да биредә үзгә – ирләрчә: биредә баталь сценалар, яу үткән урыннарның конкрет географик атамалары, корал исемнәре өстенлек итә, ә хис-тойгылар саранрак итеп бирелә.

Башкортстан татарлары репертуарында әлеге төркемгә караган өч бәет табылды. Боларның беренчесен Шаран районы Яремкә авылында Совет армиясе офицеры Миргасыйм Шакир улы Әхмәтовның (1915 елгы) Бөек Ватан сугышы елларында Габделислам әбигә (фамилиясе күрсәтелмәгән) фронттан җибәрелгән хаттан БДУ студентлары күчереп алган. Ул «Сугышта үлгән солдат бәете» [2: 241–242] дип атала һәм хикәяләү шушы солдатның күңеленнән әнисенә мөрәҗәгате – монолог төсен ала:

И әнкәем, яшь чагымда
Рәнҗеттем бит мин сине;
Герман пулялары өчен
Үстергәнсең син мине.

Миннән калган киемнәрне,
Әнкәй, үзең кисәнә.
Гомерең булса, и әнкәем,
Хәер-дога кылсана.

И әнкәем, өй алдының
Баскычлары – киң такта.
И әнкәем, күп җылама,
«Сабыр бул», – дигән китапта.

И әнкәем, саклый күрче,
Бакчадагы алмаңны.
И әнкәем, күралмадың,
Җан биргәндә, balaңны.

Икенче бәет «Сугыш бәете» дип атала. Аны 1968 елда Башкортстанның Бәләбәй районы Исмәгыйль авылында Исмәгыйль Кәлимуллиннан (1903 елгы) Риф Мөхәмmәтҗанов язып алган. Моны авылдан сентябрь аенда сугышка алынган солдатның тормыш хроникасы дип тә атарга мөмкин. Биредә аның сентябрьгә кадәр фронтка алынмавы, аннары өч кызыннан аерылып, Алкино лагеренда биш ай буена ачлы-туклы ком-таш кимереп ятуы, Финляндия чигендә хезмәт итеп, аягы яралану, бер аяксыз калуы турында бәян ителә. Шулай да бәет җиңүгә ышаныч белән тулы.

Каһәр суксын, Гитлер, сине,
Бик күп гарип ясадың;

Эшче халык күтәрелсә,
Таган ясап асарбыз.
Гитлер план корган икән
Москваны алырга;
Кызыл армия мәҗбүр иткән
Койрыгын сыртка салырга.

Өченче үрнәк – «Солдат бәете» 1963 елда Башкортстанның Миякә районы Миякәтамак авылында Нигъмәтулла Хәкимовтан (1875 елгы) БДУ студентлары тарафыннан язып алынган. Алдарак атап үтелгән үрнәкләрдән аермалы, ул 1945 елның август-сентябрендә япон империалистлары гаскәрен тар-мар итүгә багышланган. Һәм монда бәетләргә хас фаҗигалылык ул кадәр көчле түгел, чөнки төп җиңү инде яуланган, монысы – канкоешлы яуларның шаукымы гына. Бу бәет поэтикасы ягыннан оптимистик рухта булып, 1812 елгы Ватан сугышы турындагы бәетләргә якын тора. Белүебезчә, «Рус-француз сугышы бәет»ләре, жанрның башка үрнәкләреннән аермалы буларак, башыннан ахырга кадәр оптимистик рухта яңгырый. Фатих Урманче фикеренчә, «бу әлеге сугышта Русия солдатларының, Мәскәүне бер тапкыр Наполеонга биреп булса да, зур уңышларга ирешүе белән аңлатыладыр» [8: 219]. «Солдат бәете»ндә традиция буларак «Рус-француз сугышы бәет»ләренә хас булган поэтик алымнарның дәвам итүен, ягъни традицияләр күчемлелеген ачык күрергә мөмкин:

Сикереп торып киенгәч,
Урынга ут төрттек без;
Японнарны кайнап торган
Казанга утырттык без.

Җиттек япон башына,
Җиттек Гитлер башына.
Империалистлар сугыш башласа,
Үз башына шашына.

«Бәет жанрының әдәби-эстетик үсеше бигрәк тә икенче төркем бәетләр белән бәйләнгән, – дип яза Фатих Урманче. – Бөек Ватан сугышы елларында лирик бәетләр барлыкка килә: <…> әсәрләрдә үзәктә аерым вакыйгалар түгел, ә бәлки совет кешеләренең, батыр солдатның, газиз балаларын югалткан аналарның кайгы-хәсрәте сурәтләнә. Бу төр бәетләр зур тарихи вакыйгаларның аерым кеше язмышында чагылышын гәүдәләндерәләр. Аларда аерым кешенең хис-кичерешләренә зур урын бирелә. Бу төр бәетләр гүяки халык җырлары белән язма поэзиясе очрашкан урында барлыкка киләләр. Моны билгеле бер дәрәҗәдә жанрның яңа баскычка күтәрелүе дип бәяләргә мөмкин. Чөнки Бөек Ватан сугышына кадәр иҗат ителгән бәетләр арасында саф лирик әсәрләрне табу читен» [7: 369]. Мондый әсәрләр безнең классификациядәге «тыл бәетләре» төркемчәсенә туры килә.

Кайбер мисалларга тукталып үтик. 1971 елда Башкортстанның Шаран районы Алпай авылында Мөгаллимә Мөхәмммәтовадан БДУ

студентлары язып алган «Кайгылы хатын бәете»ндә сугыш чоры өчен аеруча характерлы һәм язма поэзиядә дә зур урын алган озату мотивы бөтенләй чагылыш тапмый. Бәет тәүге строфаларыннан ук ирнең үлем хәбәре белән башлана:

Кызыл армияләр саф-саф булып,
Совет илкәйләрен саклыйлар.
Кулларына мылтык, кылыч тотып,
Дошманнардан сезне яклыйлар.

Син дә шушылай кызыл армис булып
Сугыш сафларына киттеңме?
Дошманнарга каршы торам диеп,
Җаннарыңны корбан иттеңме?

Шуңа карамастан, хатыны аны көтә, көрешү турында хыяллана. Әмма сугыш беткәч, өмете өзелә. Сугыш кырында вафат булган иренә тирән ихтирам, аның истәлегенә тугрылыклы булу – геройның бердәнбер юанычы.

Һич әйтмәмен сине үлгән диеп,
Үлгән дигән хәбәр килсә дә.
Син юл алган тарафлардан монда
Салкын җилләр генә иссә дә.
.......................................................
Һич ышанмыйм сине үлгән диеп,
Үз күзләрем белән күрмәгәч.
Балаларың өзелеп шашалар,
Синнән бер дә хәбәр булмагач.

Лирик бәетләрдә геройның катлаулы кичерешләре, кайнар хисләре искиткеч тыйнак, гади итеп ачыла. Гасырлар дәвамында шигъри тәҗрибә туплап килгән халык кешенең йөрәк ярасына каты кагылырга ярамаганлыгын яхшы аңлый. Сугыш корбаннарына үзенең мөнәсәбәтен белдерү өчен отышлы шигъри алымнар сайлый. Бәетләрдә җылы лирик монолог зур роль уйный. 1998 елда Башкортстанның Туймазы районы Тукай авылында Миңлегаян Исхаковадан Айгөл Хаҗиева язып алган «Мөхәррәм бәете»ндә каты яраланган герой сугыш кырында ялгыз кала. Киеренке драматик күренеш укучының күңелен тетрәтә. Соңгы минутларында геройның йөрәген өзгәләгән уйлары әнисе турында. Ул ерактагы әнкәсен юатырга, аның хәсрәтен җиңеләйтергә тырыша, аңа җылы, ягымлы сүзләр белән эндәшә. Бу шигъри алым психологик яктан тулысынча аклана: мондый минутта иң якын, иң кадерле кешеңә башкача эндәшү мөмкин дә түгел:

Беләм, әнкәй, авыр сиңа,
Көрешүләр өмет иткәнсең;
Минем хәлләремне белер өчен,
Хатларымны өзелеп көткәнсең.

Герой туган иле, туган халкы өчен үлүен яхшы аңлый, ләкин аның яшисе килә. Бу изге теләк үтә гади сүзләр белән әйтелә: «Өйдә чакта гармунымны туйганчы уйнамадым...» Ләкин үлем рәхимсез. Моны аңлаган геройның хисләре куера, катлаулана: «Соңгы минут, соңгы секунд...» Шул мизгелдәге авыр кичерешләрне ил азатлыгы өчен үлүнең бөек мәгънәсен аңлау алыштыра:

Чәчәк гомерем өзелде,
Фашист җитте башыма;
«Хак эш өчен үлде», – диеп,
Язылсыз кабер ташыма.

Бу сүзләрдә әлеге бәет героеның гына хис-кичерешләре гәүдәләнгән дип булмый. Әсәрнең соңгы юллары ул елларда бөтен совет халкын биләгән изге тойгылар өермәсен чагылдыра. «Мөхәррәм бәете»ндә зур вакыйгалар юк, герой тормышыннан тик бер генә эпизод – яшәү белән үлем арасындагы трагик мизгел алынган һәм бөтен тирәнлеге һәм катлаулылыгы белән ачылган. Бәетнең эмоциональ яңгырашы гаять көчле.

Шуны да әйтергә кирәк: безнең тарафтан табылып, томнарга кертелгән Бөек Ватан сугыш турындагы аерым бәетләр үтә «кызыл» рәсми идеологиягә туры килми. Иҗат ителгән вакытларында аларны бастырып чыгару да мөмкин булмас иде. Мәсәлән, 1998 елда Башкортстанның Туймазы районы Тукай авылында Мөнәвәрә Гыйльмановадан Айгөл Хаҗиева язып алган «Зөбәрҗәт бәете»нең соңында аның язылу тарихы китерелә: «Зөбәрҗәт исемле кыз, 1941 елда сугыш башлангач, Сучан шахтасында эшкә җибәрелгән һәм шунда үлеп калган. Аның белән бергә эштә булган картәнием Гильманова Мөнәвәрә, ахирәтенә багышлап, бәет язган» [2: 254].

Бәет текстында үлемнең төп сәбәбе итеп сугыш чорындагы аяусыз хезмәт, крестьян хезмәтеннән көчләп аерылган гади авыл кешеләренең концлагерьлардагыча михнәтләр чигүе күрсәтелә. Биредә шулай ук XVIII гасырның беренче яртысында киң таралган «Лашман» бәетләре, ягъни Россия флоты өчен көчләп агач кисүгә җәлеп ителгән, шунда ирексез хезмәттән, сагынудан һәлак булып калган кичәге крестьяннар турындагы бәетләр белән аваздашлык нык сизелә. Марсель Бакиров, «Лашман» бәетләрен анализлап, аларда «шәхес фаҗигасы да күпчелек очракта социаль характерда» булуын ассызыклый. «Чөнки бу үлем җәмгыятьтәге социаль тәртипләр һәм төптә ятучы иҗтимагый закончалыклар нәтиҗәсендә килеп туа», – ди галим [1: 281]. Бу сүзләрне лашманчылык фаҗигаларыннан 200 елдан соң булган хәлләрне гәүдәләндергән «Зөбәрҗәт бәете»нә карата да кабатларга мөмкин. 18 яшьлек кыз, туып-үскән җиреннән аерып, Ерак Көнчыгышның күмер шахталарына алып кителә:

«Җирнең чите шушыдыр», – дип,
Башта карап тордык аптырап;

Менә Сучан[1], анда диңгез,
Находкасы[2] тора арттарак.

Шунда биш ел аяусыз хезмәттә гомер кичергәч, күмер астында калып җан бирә:

Кызлар төшә шахталарга
Кулына тотып лампасын;
Сигез сәгать буйларына
Күрми дөнья яктысын.

Өстән җир астына чаклы
Ике йөз метр ара.
Проходнойда номер гына
Чыкканны көтеп кала.

Биш ел үткәч, мин җан бирдем,
Күмер астында калып;
Җир өстенә чыгардылар,
Үлек гәүдәмне табып.

Кыскасы, «традицион бәет герое үзе яшәгән тарихи чорда хәл итәргә мөмкин булмаган төрле социаль каршылыкларны үзендә берләштерә» [1: 281].

Кыска гына гомер, бәхетсез язмышлар,
Бездән генә, әнкәй, үтмәгән,
Хәсрәт өчен туган бу кызыгыз
Монда үзе теләп китмәгән, –

ди фаҗигалы язмыш иясе.

Шулай итеп, биредә охшаш тарихи дәверләр, Россия тарихындагы кискен борылышлар чоры белән нисбәтләнгән традицияләр күчемлелеген ачык тоярга мөмкин.

«Ачлык чире бәете»н [4: 210–211] исә 2002 елда Башкортстанның Илеш районы Кадер авылында Фәнүзә Гыйльвановадан БДУ студенты Альмира Хәйретдинова язып алган. Бәетнең керешендә аның язылу тарихы китерелә: «1944 елны, сугыш вакытында, халык бик ачыкты һәм, көз көне җыелмый калган арыш башагын ашап, бик күп кеше агуланды, үлде. Бик күп өйләр йозакка бикләнде». Бу үзе үк бәетләрнең рәсми, халык героизмын гына чагылдырган әсәрләр булуыннан бигрәк, чын тарихның, канлы-яшьле тарихның халык күңелендәге образлы гәүдәләндерүенә дәлил.

Алтмыш өйле бер авылда
Кырыклап кеше үлде;
Көн саен дүрт-биш мәетне
Исән кешеләр күмде.

---

[1] Сучан – Приморск краендагы шәһәр; 1932–1972 елларда – Сучан, аннан соң Партизанск дип атала.

[2] Находка – Приморск краендагы шәһәр-порт.

Иртән чирли баласы –
Тамаклардан кан килә;
Ә кичен чирли анасы –
Танаудан да кан килә.

Өйдә бер кеше чирләсә,
Өйдә беркем калмады.
Үлем канатларын җәеп,
Безне кайгы ялмады.

Безнең Базы[1] суы әче,
Үрчетеп булмый балык.
Сугышта кеше кырылды,
Авылда үлде халык.

Биредә бик уңышлы параллель – яу кырын ул чордагы авыл тормышы белән тәңгәлләштерү күзгә ташлана. Аларның икесендә дә яшәү өчен сугыш бара. Беренчесендә – дошман ачык, немец фашисты булса, икенчесендә ул – күзгә күренмәс; ачлык һәм көздән калган башак ашаудан килеп чыккан кан чире.

Шуңа колхоз бригадирларының аяусызлыгы да килеп кушыла:

Үлгәннәр кабере яныннан
Үтәбез башны иеп;
Исән чакта җир сөрделәр,
Сауган сыерны җигеп.

«Сыерыңны җик!» – дип куша
Яшенә дә картына;
Тырма тартып, без йөрибез
Әниләрнең артыннан.

Яу кырында да, тыныч тормышта да бихисап корбаннар биреп яулап алынган тынычлыкны саклау, аның бозылуына юл куймау – бәетче өчен төп бурыч булып тора. Шуңа да ул:

Сабан сөреп, тырма тартып,
Без яшәргә тырыштык;
И Ходаем, илгә-көнгә
Бирсәң иде тынычлык, –

дип ялвара.

Шуны әйтергә кирәк: ил киңлекләрендә дә, дөньяда да сугышларның әлегә кадәр тынып торганы юк. Хәрби-тарихи бәетләр, халык иҗатының актив һәм хәрәкәтчән жанр төре буларак, теге яки бу төбәктә бәхетсезлеккә очраган һәм вакытсыз якты дөньядан киткән кешеләргә аталып, бүген дә актив иҗат ителеп тора. Әлеге төр бәетләрдә без илкүләм тарихи вакыйгаларга багышланган бәетләрдәге панорамалык сыйфатының шәхси фаҗигалар турындагы бәет

---

[1] Базы – Башкортстанның Шаран, Чакмагыш, Илеш һәм Дүртөйле районнары буенча агып, Агыйделгә коя торган елга.

поэтикасы белән үрелеп китүен күрә алабыз. Бөек Ватан сугышы турындагы бәетләр, татар халкы өчен генә түгел, бөтен ил күләмендәге тетрәнүләрне, фаҗигаларны чагылдырган поэтик әсәрләр булып торалар һәм бүгенге көндә дә үзләренең сәнгати-эстетик кыйммәтләрен югалтмыйлар.

**Әдәбият**

1. *Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. 359 б.

2. Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / төз., кереш мәкалә һәм аңлатмалар авт. И.К. Фазлетдинов; ф. ред. К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 312 б.

3. Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төз., кереш мәкалә һәм аңлатмалар авт. И.К. Фазлетдинов; ф. ред. К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

4. Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төз., кереш мәкалә һәм аңлатмалар авт. И.К. Фазлетдинов; ф. ред. К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 304 б.

5. Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 9: Баиты / сост.: Ф.В. Ахметова, И.Н. Надиров, К.Б. Замалетдинова; отв. ред. И.К. Фазлутдинов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2022. 479 с.

6. Татар халык иҗаты. Бәетләр / төз. Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 352 б.

7. *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2005. 383 б.

8. *Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: 3 томда. 1 т. (А–Г). Казан: Мәгариф, 2008. 303 б.

***Фазлетдинов Илдус Камил улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Уфа Фән һәм технологияләр университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы доценты*

***Фазлутдинов Ильдус Камилович,***
*кандидат филологических наук, доцент;*
*доцент кафедры татарской филологии и культуры Уфимского университета науки и технологий*
*fazlutdinov75@mail.ru*